КӨТЕЛГӘН ШАТЛЫК

Кукмарада – өй туе

> 2

ТҮЛӘҮЛЕ МЕДИЦИНА

Сыйфатсыз хезмәт өчен акчаны ничек кире кайтарырга?

> 3

АККАУНТЛЫ АВЫЛЛАР

Читтә яшәүчеләр онлайн берләшә

> 4

ШАТЛЫКЛЫ ДА, БОРЧУЛЫ ДА

Кышкы Олимпиада нилəр белән истә калды?

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 23 (28796) | Чәршәмбе | 16 февраль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

ӘНИГӘ ДӘ, БӘБИГӘ ДӘ ЯРДӘМ

Республикада һәр ике сумның берсе балалы гаиләләргә ярдәм күрсәтүгә тотыла. Татарстан хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова шулай дип ышандыра. Социаль ярдәм чараларының ни дәрәҗәдә нәтиҗәле булуын рәсми саннар да раслый. Әйтик, соңгы ун ел эчендә Татарстанда күпбалалы гаиләләр саны ике мәртәбә арткан.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Шөкер, дибез

Танылган җырчылар – Илназ Бах белән Гүзәл Идрисова – күпбалалы әти-әниләр сафында. Өч ул үстерүче җырчы пар бүген дәүләт тарафыннан бирелгән күп кенә социаль ярдәм чараларыннан файдалана. «Балалар кечерәк чакта бушлай сөт ризыгы ала идек. Бик рәхәт булды. Бүген төпчек улыбыз балалар бакчасына йөри. Күпбалалы гаилә буларак, анда тиешле сумманың яртысын гына түлибез. Безгә салым түләгәндә дә ташлама ясала. Җир яки милек салымының икесенең берсен генә түлибез. «Ана капиталы» программасы ярдәмендә торак шартларын да яхшырттык, Аллаһка шөкер. Болар бар да күпбалалы гаиләләргә бик зур ярдәм», – дип сөйләде «ВТ» хәбәрчесенә Гүзәл Идрисова.

Татарстан хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова сүзләренә караганда, соңгы елларда республикада өч һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләр саны арта бара. «2012 елда республикада 24,8 мең күпбалалы гаилә исәпләнгән булса, ун елдан соң аларның саны ике тапкыр артты. Бүген республикада 40,5 мең күпбалалы гаилә яши. Монда республикада әлеге гаиләләргә билгеләнгән түләүләрнең дә өлеше зур», – ди министр.

Билгеле булганча, бүген Татарстанда аз керемле күпбалалы гаиләдә тәрбияләнүче өч яше тулмаган сабыйларга дару алу өчен 10 мең сумлык сертификат бирелә. Бала туган очракта мондый гаиләгә 9 мең сумлык бала кирәк-ярагы комплекты бүләк итәләр. Айлык кереме яшәү минимумыннан кимрәк булган күпбалалы гаиләдә тәрбияләнүче сабыйларны бакчага йөртү бушлай. Моннан тыш аз керемле күпбалалы гаиләләргә айлык пособие дә түләнә.

Эльмира Зарипова сүзләренә караганда, бүген Татарстанда социаль ярдәм чараларына 24,7 миллиард сум акча каралган. Шуларның 11,6 миллиард сумын балалы гаиләләргә матди ярдәм күрсәтүгә тотарга җыеналар. Аларның 6,9 млрд сумы – федераль, 4,7 млрд сумы республика бюджетыннан бирелә. «Татарстанда һәр ике сумның берсе балалы гаиләләргә матди ярдәм күрсәтүгә тотыла», – ди министр.

Үзе дәрәҗә, үзе ярдәм

Быел Татарстанда беренче балага бирелә торган айлык пособие күләме 10433 сумга җитте. 2018 елдан бирле гамәлдә булган әлеге акчалата ярдәм беренче баласы туган яисә тәрбиягә бала алган, айлык кереме төбәктәге ике яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләргә бирелә. Беренче балага каралган пособие быел 37,7 мең кешегә биреләчәк.

3 яшьтән 7 яшькә кадәр пособие баштарак төбәктә балалар өчен билгеләнгән яшәү минимумының яртысы күләмендә түләнә иде. Узган елның апрелендә аны исәпләү кагыйдәләре үзгәртелде. Хәзер аның күләме, гаиләнең айлык керемен карап, 50 процентка гына түгел (быел – 5216 сум), ә төбәктәге балалар өчен каралган яшәү минимумының 75 проценты (7824 сум) һәм 100 процентына (10433 сум) кадәр җитәргә мөмкин.

«2021 елның 1 июленнән яңа түләүләр кертелде. Матди хәле авыр булган йөкле хатыннарга хәзер өстәмә пособие түләнә. Моның өчен гаиләдә җан башына туры килгән айлык керемнең төбәктәге бер яшәү минимумы күләменнән азрак булуы шарт. Шуннан чыгып, йөклелекнең 6–12 атнасында исәпкә баскан, матди хәле авыр булган булачак әниләргә 5862 сум күләмендә пособие түләнә. 8–17 яшьлек баласын ялгызы гына тәрбияләүче ата-аналарга 6200 сум пособие бирү каралган», – ди Эльмира Зарипова. Сүз уңаеннан, быелдан башлап күп кенә социаль ярдәм чаралары социаль яклау органнарыннан Пенсия фонды карамагына тапшырылды. Әйтик, бала туганда бер тапкыр бирелә торган, балага 1,5 яшь тулганчы түләнелүче пособиеләрне хәзер Пенсия фонды аша аласы.

Ахыры 2 нче биттә >

2 градуска кадәр җылыта

Татарстанга яз якынлаша. Республика Гидрометеоүзәге фаразларына караганда, инде бу атна ахырында ук «плюс»лы температура күтәрелә.

Пәнҗешәмбе – 17 февральдә явым-төшем булмый диярлек. Көндез – 1–6, төнлә 6–13 градус суык. Җомгада һава торышы үзгәрә. Көнбатыш районнарда кар, урыны белән буран, секундына 15–20 метр тизлектә көчле җил. Көндез –4...+1 градуска кадәр җылытса, төнге сәгатьләрдә термометрның терекөмеш баганасы 2–7 градуска кадәр төшәчәк. Гидрометеоүзәкнең башлангыч мәгълүматларына караганда, ял көннәре – 19 һәм 20 февральдә юеш карлы-буранлы, җилле (секундына 15–20 метр тизлектә), җылы һава фаразлана. Һава температурасы +2...–3 градус булачак.

Ничарадан бичара

Татарстанда суд приставлары бер ирдән 820 мең сумнан артыграк алимент түләткән. Дүрт ел буе балаларына бер тиен акча бирмичә яшәгән ул. Шушы вакыт эчендә 820 мең сумнан артыграк бурычка баткан. Ваемсыз ата чит илгә чыга алмагач кына сабыйларына әҗәтен түләргә мәҗбүр булган. Балаларын бар дип тә белмәсә дә, чит кыйтгага юлны япмасыннар өчен, акчаны бик тиз тапкан: шуның кадәр зур сумманы берьюлы түләп куйган.

Сүз уңаеннан, хәзерге вакытта республикада 110 меңнән артыграк кеше бурычын түләмәү аркасында илдән чыгып китә алмый. Шуның 10,5 меңе – алимент түләмәүчеләр.

Көнләп түгел, сәгатьләп үсә

Республикада еллык инфляция күрсәткече гыйнвар аенда 8,9 процентка җиткән. Елның беренче аенда ул 0,8 процентка арткан. Татарстанстат сайтында шулай дип хәбәр ителә. Азык-төлек хакы 2021 елның декабрендәге белән чагыштырганда 1,5 процент чамасы арткан. Бер елда бәяләр 11,5 проценттан күбрәккә үскән.

Сәнәгать товарларына килсәк, узган айда алар 0,4 процентка (бер ел эчендә – 9,2 процентка) кыйммәтләнгән. Хезмәтләр бәясе 0,5 процентка (бер ел эчендә – 5 процентка) арткан. Белгечләр әйтүенчә, озакламый сөт һәм сөт ризыклары да кыйммәтләнергә мөмкин.

Ришвәт түгел рәхмәт

Узган елда Татарстанның ЮХИДИ хезмәткәрләренә 454 тапкыр ришвәт тәкъдим иткәннәр. 84 очракта инспекторларга акча сузганнар. ЮХИДИ идарәсеннән хәбәр итүләренчә, хокук бозуга юл куймаганнар. Быел автоинспекторларга 50 тапкыр ришвәт бирмәкче булганнар. 7 очракта йөртүчеләрне полиция хезмәткәренә акча сузганда тотканнар. Әйтик, 30 гыйнвар көнне Казанда Daewoo машинасын йөртүче (учеттан төшерелгән автомобиль белән идарә иткән өчен туктатылган) автоинспекторларга акча тәкъдим иткәндә тоткарланган. Аңа карата «Ришвәт бирү» статьясы буенча җинаять эше кузгатылган. Февраль аенда тәртип сакчылары Казанда яшәүче тагын бер ир-атның юлына аркылы төшкән. Монысының иминият полисына ия булмаган килеш рульгә утырганы ачыкланган. Килеп туган хәлдән ЮХИДИ инспекторларына акча төртеп котылмакчы булган.

ЮХИДИ идарәсе башлыгы урынбасары Алексей Пономарев искә төшереп үткәнчә, вазыйфаи затка ришвәт бирү иректән мәхрүм итүгә дә китерергә мөмкин.

Илкүләм проектлар

Укытырга яңасы кирәк

81,6 млн сумга – 1134 ноутбук. Татарстандагы мәктәп һәм көллият укытучыларының замана җиһазларын яңартырга җыеналар. Ноутбук өчен акча «Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль программасы кысасында бүлеп биреләчәк. Бер ноутбук 72 мең сумга төшәчәк.

tatarstan.ru

Сүз уңаеннан, белем бирү тармагында цифрлы мөмкинлекләрне гамәлгә кертүгә юнәлдерелгән әлеге федераль проект кысасында 2024 елга кадәр 29,5 мең мәгариф учреждениесенең матди-техник базасын яңартырга ниятлиләр.

Дөрес, Татарстанда моңа кадәр дә укытучыларны замана техникасы белән тәэмин итүгә бәйле программалар тормышка ашырылып килде. Мәсәлән, «Мәктәпкә – компьютер», «Укытучыга – компьютер». Бу программалар кысасында 450 млн сум акча тотылган. 2010 елда – 25820, 2011 елда 19600 ноутбук сатып алганнар иде. 2015 елдан исә шул чорда сатып алынган ноутбукларны яңартырга тотындылар. 40 меңләп укытучыга яңа җиһаз бирделәр.

Илкүләм проект кысасында сатып алыначак 1134 ноутбук Татарстанның 52 мәгариф учреждениесендә белем бирүче укытучылар өлешенә тиячәк. Аз комплектлы мәктәпләр дә игътибарсыз калмас дип ышандыралар. Укучылар саны аз булган район мәктәпләренә (Әгерҗе, Аксубай, Чирмешән, Апас, Теләче, Кукмара, Балык Бистәсе, Буа, Мамадыш, Азнакай, Лаеш, Алексеевск, Югары Ослан) – бишәр, Казандагы белем йортларына 28әр ноутбук бирәчәкләр.

Мәктәпләр белән беррәттән көллиятләргә дә уңыш елмаячак. 28әр ноутбукны Казандагы педагогия, Бөгелмәнең аграр, Әлмәт көллиятләре, Чистайның авыл хуҗалыгы, Лениногорскидагы нефть техникумнары, Түбән Каманың Лемаев исемендәге уку йорты алачак.

Цифрлаштыру елында мөгаллимнәрнең эшен җиңеләйтү моның белән генә чикләнмәс анысы.

Татарстанның дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин хәбәр иткәнчә, аларның хисап эшен киметү юлларын да эзлиләр.

– Укытучылар дәрестән соң төрле хисап тутыруга бик күп вакыт сарыф итә. Без Мәгариф министрлыгы белән бергә аларны кәгазь эшеннән азат итү, бу эшне автоматлаштыру бурычын куйдык, – диде ул.

Моңа өстәп республика банкларының берсе ярдәме белән укытучылар өчен 24 мең ноутбук сатып алу күздә тотыла. «Мин – мәктәп укучысы» кушымтасына да яңалыклар өстәячәкләр. Әлегә кадәр аның ярдәмендә укытучы белән элемтәдә торырга, дәрес билгеләрен белергә, өй эшләре турындагы мәгълүмат белән танышырга мөмкин иде. Якын арада моңа читтән торып психологик ярдәм алу хезмәтен дә өстәргә ниятлиләр.

Сүзгә-сүз

Эдуард ЛАТЫЙПОВ, Россия биатлончысы:

Начар мизгелләрне дә яхшыга үзгәртергә, алардан тагын да көчлерәк булырга ярдәм итәрлек сабак ала белергә кирәк. Хаталарсыз яхшырак та, чемпион да була алмыйсың. Миңа калса, теләсә кайсы бөек спортчының хаталанган чаклары булгандыр. Беркайчан да тукталмаулары, һәрчак алга барулары аркасында бөек булган алар.

(Эстафета ярышында алтын медальне кулдан ычкындыргач әйткән фикере)

ИЛ ХАЛКЫН НӘРСӘ БОРЧЫЙ?

«Общественное мнение» фонды Россиядә яшәүчеләрдән әнә шул хакта сорашкан. Нәтиҗәләрдән күренгәнчә, ил халкын сәламәтлек мәсьәләсе, бәяләр һәм яңа чирләр килеп чыгу борчуга сала.

- 54% → якыннарымның сәламәтлеге
- 42% → яңа эпидемияләр
- 40% → бәяләрнең үсүе
- 39% → балалар һәм оныклар өчен борчылам
- 33% → үземнең саулыгым

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КҮЗЛӘРЕМӘ БЕР КАРАВЫҢ ҖИТӘ...

Үткән атна ахырында Россиянең көнбатыш чикләрендә башланып киткән киеренкелек берникадәр йомшарды. Мәскәүдә Путин тышкы эшләр министры Лавров һәм оборона министры Шойгу белән озын өстәл янында утырып сөйләшкәннән соң, Кремль Көнбатышка үзенең сөйләшүләрне дәвам итәргә әзер икәнлеге турында сигнал бирде.

Өстәлнең бик озын булуын Президент сүзчесе Песков әфәнде Президентның ковид-чикләүләрне төгәл үтәве белән аңлатты. Бу – сөендерә торган факт, чөнки Көнбатышта Россия атом-төш сугышы башларга мөмкин дип куркыталар бит. Владимир Владимирович үзе дә сугыш башлана калса, берәүнең дә исән калмаячагын ассызыкларга ярата. Президентның үз сәламәтлегенә зур игътибар белән каравы аның зур һәлакәткә китерүче адым ясамаячагын искәртә безгә. Дүшәмбедә Россия җитәкчелегенең күзгә-күз карап утырып сөйләшүе һәм ул сөйләшүдән соң ясалган игъланнар финансларга уңай тәэсир ясады. Түнеп баручы биржа индекслары түбән төшүне акрынайтты, сум долларга карата бераз ныгыды. Әмма бер нәрсә күзгә ташлана: бөтен дөньяда биржалар кызыл зонада, ягъни куыклар акрын гына, әмма даими шиңү юнәлешендә. АКШ ФРСы быел процент ставкасын күтәрергә тиеш. Ставка күтәрелсә, фонд базарында түбәнәю көчәячәк. Бу хәл – финанс тотрыксызлыгы зур сугышка этәрүче төп фактор булып торачак.

Дүшәмбе көнне Германия канцлеры Шольц Зеленский белән очрашты. Украинага финанс ярдәме, Россиягә исә, конфликтны көчәйтсә, каты санкцияләр вәгъдә ителде. Зеленский: «Украина иминлеге – Европа иминлеге», – дип игълан итеп, Көнбатышның киң җилкәсе артына качарга теләк белдерде. Украина Президенты ил гражданнарына мөрәҗәгать белән дә чыкты. Мөрәҗәгатендә ил армиясенең куәтле булуы хакында сөйләде, Донбассны да, Кырымны да кайтарып алырга вәгъдә бирде. Әмма кулдан ычкынган төбәкләрнең кире кайтуы дипломатик сөйләшүләр юлы белән булачагын искәртте.

Немец канцлеры да Киев белән Мәскәүнең йөзгә-йөз, күзгә-күз очрашып сөйләшү оештыру ягында булуын белдерде. Очрашу әзерләнә ул әзерләнүен. Төркия лидеры Әрдоган Путин белән Зеленскийны үз янына чакырды. Кремльдә ул чакыруны кабул иттеләр дигән хәбәр бар. Киев очрашуга Донбассның аерым статусы турындагы закон проектын күтәреп килергә тиеш. Мәскәү шундый шарт куя. Украинада, ниһаять, ул закон проектын әзерләргә ризалык бирделәр. Әмма Көнбатыш лидерлары Мәскәүдән чик буендагы гаскәрләрне алуны таләп итә.

Көнбатыш чикләрдә киеренкелек бер үсеп, бер кимеп ятканда, «Талибан» (Россиядә тыелган террорчы оешма) заманча коралланган ун меңлек гаскәрне Таҗикстан һәм Үзбәкстан чикләренә китереп урнаштыруы хакында игълан итте. Әфган кораллы көчләре генштабы җитәкчесе Фитрат сүзләренә таянып, Россия мәгълүмат чаралары әнә шундый хәбәр тарата. Бу төбәктә киеренкелек башланса, Россиягә читтә калу кыен булачак, чөнки чикләр – ОДКБныкы.

Россиядә

МАТРАС АСТЫНДАГЫ ТРИЛЛИОННАР

Соңгы вакытларда Россия банкларында акча кытлыгы күзәтелә. Россиядә 2016 елның 1 гыйнварыннан бирле «Базель III» дип йөртелгән банк көйләве гамәлдә. Ул кертем ияләре банклардан акча таләп итә башласалар, финанс оешмасыннан 30 көн буена ул таләпне канәгатьләндерерлек югары ликвидлы активларга ия булуны аңлата.

Югары ликвидлы актив дип сатып тиз генә акчага әйләндереп була торган кәгазьләрне атыйлар. Менә шундый ликвидлыкка ия булмаган банкларга Үзәк банк үз җилкәсен куя, ягъни акча басып өләшә. Пандемия кризисы башланган 2020 елда Үзәк банк кайбер айларда банкларның триллионлык ихтыяҗларын акча басып канәгатьләндергән. Андый калҗадан гадәттә зур әһәмияткә ия дип саналган җиде банк авыз итә икән. Алар алган шундый ярдәм 2,5 триллион сумга җиткән. Физик затлар депозитлардагы акчасын алган саен Үзәк банк зур банклар казанына акча басып ыргытып торган.

Шундый шартларда инфляция үсми кая барсын инде? Банк регуляторы быелның гыйнварында азык-төлек инфляциясенең 11,1 процентка җитүен әйтә әнә. Төп ставканы күтәргәч, кешеләр яңадан акчасын депозитка сала башлаган башлавын. Декабрь аенда гына да депозитларга 1,571 триллион сум акча килеп кергән һәм банклар Үзәк банктан алган триллионнарның яртысына якынын кайтарып биргән.

Әмма бик күп кәгазь акча банклар карынында түгел, кешеләр кулында йөри, имеш. Рәсми мәгълүматлар, россиялеләр акчаны банкка түгел, матрас астына сала, дип әйтә. Кешеләр 14,1 триллион сум акча өстендә йоклый, диләр акча санарга яратучы Росстат белгечләре. Бу Милли байлык фондыннан (ФНБ) да күбрәк. Соңгысында бары тик 13,6 триллион сум гына бар икән. Барлык төбәкләрнең бюджетын бергә кушкач та, матрас астындагы акчадан аз гына күбрәк чыга, ди. Төбәкләрнең гомуми бюджеты – 16,8 триллион сум.

Банкларга илтергә теләмәгән һәм биржада да уйнарга яратмаган акчаның 61 проценты, ягъни 8,7 триллион сумы Үзәк банк баскан купюраларда саклана. 5,425 триллион сумны – 74,6 миллиард долларга тиң акчаны чит ил валюталарына әйләндереп, матрас астына түшәгәннәр. Ә менә банк депозитларында физик затлар 92,8 миллиард доллар саклый.

Соңгы ике елда халык кулындагы акча 30 процентка арткан. Үзәк банк баскан барлык акча – 3,3 триллион сум шулай шәхси кулларга күчкән. Халык депозитларның процентлары түбән булудан зарланып, акчаны кулда тотуны сөя төшкән. Эш яшендәге халыкның зур күпчелеге кредит камытын сөйрәп баруын исәпкә алганда, матрас астындагы акчаның ияләре кемнәр икәнен чамаларга була булуын. Кибеттән азык-төлекне яздырып алучы авыл кешесе дә акча өстендә төш күрә дип әйтеп булмый.

Үзәк банк ставканы күтәргәч, акча депозитларга күчә башлар дип фаразлыйлар фаразлавын, әмма кулга кыек юл белән кергән акча банк ишегеннән кермәс, мөгаен. Кулда тотылган акчаның байтагы – килеп чыгышын яшергән капитал дип уйларга нигез бар.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Рөстәм Миңнеханов Казанда 2022 елгы ир-атлар командалары арасында волейбол буенча дөнья чемпионаты матчларын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитетының икенче утырышын уздырды.

«Безнең максат – Казандагы матчларны иң югары дәрәҗәдә уздыру. Моның өчен республикада барлык кирәкле ресурслар һәм зур спорт чараларын оештыру тәҗрибәсе бар», – диде Президент утырышта.

Казанда узачак матчларга 2 меңнән артык билет сатылган инде. Төп җанатарлар – Россия, Польша һәм Казахстаннан. Әлегә билетларның сатуга яртысын гына чыгарганнар. Бу эпидемиологик вазгыять аркасында кабул ителергә мөмкин булган чикләүләргә бәйле.

Дөнья чемпионаты 2022 елның 26 августыннан 11 сентябренә кадәр Мәскәү, Санкт-Петербург, Калининград, Ярославль, Казан, Уфа, Екатеринбург, Новосибирск, Кемерово һәм Красноярск шәһәрләрендә узачак. Татарстан башкаласында икенче төркем этабының 6 уены булачак.

КЫРГА ЧЫГАРГА, ХАЛЫКНЫ ТЫҢЛАРГА

tatarstan.ru

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Әлмәткә эшлекле сәфәр кылды. Биредә ул район Советы сессиясе эшендә, Урсала микрорайонында балалар бакчасын ачуда катнашты, шулай ук нефтьчеләр шәһәрендә яшәүчеләр белән аралашты.

Парламент башлыгының эшлекле сәфәре «Русалочка» балалар бакчасы белән танышудан башланды. Әлмәттә аның ачылышын инде күптән көткәннәр. Соңгы вакытларда халык саны арта барган әлеге зур микрорайонда әлегәчә бер генә бакча эшләгән. «Русалочка» 140 баланы кабул итәргә әзер. Биредә алты төркем эшләячәк. Авыррак сөйләшүче сабыйларга аерым логопедия төркеме дә булдырылган. Фәрит Мөхәммәтшин балалар бакчасы мөдиренә уенчыклар сатып алу өчен сертификат тапшырды.

Узган елның эш йомгакларына багышланган хисап сессиясе «Әлмәт» иҗтимагый үзәгендә узды. Район хакимияте башлыгы Тимур Ногманов әйтүенчә, узган ел нефтьчеләр шәһәре өчен шактый ук уңышлы булган. Район республиканың социаль-икътисади үсеш рейтингында беренче өчлеккә кергән. Биредә Татарстанның бөтен сәнәгать продукциясенең өчтән бер өлеше чамасы җитештерелә. Әлмәт районы – тулаем территориаль продукт күләме ягыннан – икенче урында. Социаль инфраструктура өлкәсендә күп кенә проектлар «Татнефть» компаниясе акчасына тормышка ашырыла.

Тимур Ногманов җәмәгать транспорты проблемасына аерым тукталды. Район башлыгы, бизнесның әлеге төренең предприятиеләр өчен табышлы булмавын искәртеп, республика җитәкчелегенә муниципаль җәмәгать транспорты мәсьәләләрен төрле яклап хәл итү мөмкинлеген карау үтенечен җиткерде. «Транспорт оешмалары, чыгымнарны тиешенчә компенсацияләү мөмкинлегенә ия булмау сәбәпле, һәр нәрсәдә экономияләргә мәҗбүр», – диде ул.

Фәрит Мөхәммәтшин үзенең чыгышында иң элек Әлмәткә – үзенең туып-үскән районына килгән саен аерым бер хисләр кичерүен искәртте. «2021 елдагы кыенлыкларга карамастан, әлмәтлеләр республика икътисадына лаеклы өлеш кертте», – дип билгеләп үтте парламент башлыгы.

Әмма авыл хуҗалыгын үстерү ягыннан Әлмәт 43 район арасыннан 40 нчы урында гына бара. «Мин бу җәһәттән кимчелекләр, файдаланылмый килүче мөмкинлекләр турында сөйләргә мәҗбүр. Сезнең басу-кырлар начар түгел. Авылда яшәүчеләр саны кимү аңлашыла анысы. Татарстанда гына түгел, бөтен ил күләмендә шулай. Әмма ничек кенә булмасын, авыл хуҗалыгы мәсьәләсе белән шөгыльләнергә, барлык мөмкинлекләрне эшкә җигәргә кирәк», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Дәүләт Советы Рәисе район сессиясендә гражданнар мөрәҗәгатьләре һәм сайлаучылар наказлары белән эшләүгә аерым игътибарын юнәлтте. «Сигезенче чакырылыш Дәүләт Думасы депутатларын сайлау алдыннан 6 меңнән артыграк сайлаучылар наказын алдык. Бик зур сан бу. Без бер генә мөрәҗәгатьне дә игътибарсыз калдырмаячакбыз. Сезнең – җирле идарәдәге наказлар. Аларның берсенең генә дә игътибарсыз калмавы мөһим», – диде ул.

Әлмәттән соң Фәрит Мөхәммәтшин Бөгелмәгә юл тотты. Ул районның хисап сессиясе утырышы йомгаклары турында сөйләп, болай диде: «Районның икътисади, социаль һәм мәдәни тормышындагы бурычларны хәл итүдәге уңай үзгәрешләрне билгеләп үттем. 2019 елда узган хисап сессиясендә район җитәкчелеген тәнкыйтьләгән булсам, быел Бөгелмәнең үсеш буенча җитди адым ясаганын күрдем. Иң мөһиме – кешеләрнең кәефе яхшырган. Моңа мин сәфәр барышында инандым».

Әнигә дә, бәбигә дә ярдәм

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Министр күпбалалы гаиләләргә ярдәм чаралары турында сөйләгәндә, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов карары нигезендә республикада кертелгән «Ата-ана фидакарьлеге» медален тапшыру шартларына да аерым тукталды. Ул җиде һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләгән гаиләләргә тапшырылачак. Бүләккә Татарстанда кимендә 10 ел яшәүче, сәламәт яшәү рәвеше алып баручы, балаларның сәламәтлеге, рухи һәм әхлакый үсеше турында кайгыртучы үрнәк гаиләләр дәгъва кыла ала. «Ата-ана фидакарьлеге» медале белән бүләкләнгән ата-аналарның берсенә 100 мең сум күләмендә бер тапкыр акчалата бүләк бирелячәк», – ди Эльмира Зарипова.

Фәкыйрьлек чабудан тартса

Бүген Татарстанда 254 мең кеше хәерчелек чигендә яши. Шуларның 72 процентын балалы гаиләләр тәшкил итә. Хәерчелек чигендә яшәүчеләр дигәндә айлык кереме яшәү минимумыннан – 10756 сумнан азрак булган гаиләләр күздә тотыла. Мондый кыен хәлдә калган гаиләләргә ярдәм йөзеннән республикада социаль контракт программасы эшли. Хәерчелек чигендә яшәүче гаилә белән 9 айга килешү төзелә. Шушы вакыт эчендә хөкүмәт аларга ай саен билгеле бер күләмдә акча түләп тора. Шул вакыт эчендә гаилә әгъзалары тормыш шартларын яхшырту өчен кулыннан килгәннең барысын да эшләргә – эшкә урнашырга, үз эшен ачарга, яңа һөнәр үзләштерергә яисә сәламәтлеген яхшыртырга тиеш. Быел Татарстанда 300дән артык социаль контракт төзелгән. Узган ел әлеге программа ярдәмендә 28,7 мең гаилә яшәү шартларын яхшырткан.

Хәерчелек чигендә яшәүче гаиләләрне якын киләчәктә махсус реестрга да кертергә мөмкиннәр. Россия Дәүләт Думасына керткән яңа закон проекты авторлары моны Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү мәгълүмат системасы аша эшләргә тәкъдим итә. «Хәзерге вакытта халыкның керем дәрәҗәсе, хәерчелек чигендә яшәүчеләр саны Росстат идарәсе уздырган тикшеренүләр нигезендә генә исәпләнә. Ул мәгълүматлар исә рәсми документлар нигезендә түгел, күбрәк кешенең үзе сөйләгәннәре нигезендә туплана. Шуңа күрә махсус реестр бик кирәк», – ди проект авторлары.

Йортына газ үткәрү мәшәкатьләре белән йөргән кешеләргә дә ярдәм вәгъдә итәләр. «Быел газны участокка кадәр китерү һәм газ җиһазларын сатып алуга бер тапкыр бирелә торган субсидия түләү турында карар да кабул ителде», – ди Эльмира Зарипова. Әлеге субсидия узган елның 21 апреленнән соң газ тоташтыру турында килешү төзегән кешеләргә биреләчәк. Бөек Ватан сугышы ветераннары, күпбалалы гаиләләр, I һәм II төркем инвалидлар, инвалид бала тәрбияләүче гаиләләр, җан башына уртача кереме 10000 сумнан кимрәк булган гаиләләр өчен субсидия күләме – 80000, җан башына уртача кереме 10000 сумнан 19000 сумга кадәр булган гаиләләр өчен 60 мең сум тәшкил итә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

«АВЫЛ ЭШЛЕ ДӘ, ЙОРТЛЫ ДА ИТТЕ»

ВАХИТТА ИКЕ ГАИЛӘ ТОРАКЛЫ БУЛГАН

Кукмара районының Вахит авылында яшәүче ике яшь гаиләгә «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасы буенча йортлар салып биргәннәр. Яшьләрнең барысы да «Вахит» хуҗалыгында эшли. Шунысы игътибарга лаек: егет һәм кызларның барысы да – кайчандыр шәһәрдә, район үзәгендә яшәп, киләчәкләрен авыл белән бәйләүчеләр.

Рәмилә һәм Таһир Галимуллиннар гаиләсе бер малай тәрбияли. Рәмилә хуҗалыкта икътисадчы ярдәмчесе булып эшли. Таһир хуҗалык җитәкчесен йөртә.

Рәмилә әйтүенчә, әлеге программага яшьләр 2020 елда баскан булганнар. Инде бер елдан соң йортны салып бетереп тапшырганнар да. Программа 80/20 исәбеннән тормышка ашырыла. Ягъни йорт салу чыгымнарының 80 процентын дәүләт күтәрсә, калганына хуҗалык үз өлешен кертә. Йортның мәйданы – 72 квадрат метр.

– Программа артыннан йөргәндә дә авырлыклар белән очрашмадык. Бер ай эчендә документларны җыеп тапшырдык. Авыл Советы да бик булышты. Һәр яктан да таләпләр үтәлгәч, шунда ук ризалык бирделәр. Беренче чиратта икебезнең дә колхозда эшләвебезгә игътибар иттеләр. Икенчедән, бер кешегә туры килә торган квадрат метрлар аз булды, чөнки бер түбә астында җиде кеше яшәдек, – диде Рәмилә Галимуллина.

Шулай ук программага керер өчен хезмәт елларына да игътибар итәләр. Эш стажы 5 елдан арткан булса, тагын да яхшырак.

– Әбинең төп нигезен бетермәс өчен, йортны аның участогына салдык. Аны төзеп бирсәләр дә, барысын да үзебез контрольдә тоттык. Әтиебезнең кулы эш белгәч, ул аеруча тырышты. Йорт салганда аның да өлеше зур булды. Үзебездән бер тиен дә чыгым китмәде. Гаиләбез мондый зур эшне тиз арада башкарып чыга алмаган булыр иде, – ди хуҗабикә.

Ире дә, үзе дә шушы авылныкылар. Берничә ел Казанда яшәгәннәр. 2017 елда авылга күченеп кайтып, хуҗалыкка эшкә урнашканнар. Моңа кадәр яшьләр Таһирның әтиәнисе белән бергә яшәгән. Быел җәен исә үз куышларына күченергә уйлыйлар.

– Без бүгенге тормышыбыздан бик канәгать, – ди яшь белгеч. – Авылда да шәһәрчә яшәп булганын аңлагач, Вахитка кайтып төпләнергә булдык. Безнең авыл бик зур, матур, төзек. Иң мөһиме – икебезнең дә эш урыннарыбыз бар. Улыбыз ясле төркеменә йөри. Аны анда 1,3 яшьлек чагында ук бирдек. Киләчәктә дә авылда торырбыз, дип уйлыйбыз. Биш елдан соң йортны да үзебезгә рәсмиләштерергә телибез.

Вахит авылында мондый бәхет ике гаиләгә берьюлы тәтегән. Аларга кадәр хуҗалыкта биш гаилә шушы ук программа буенча үз куышларын булдырган. Икенче яшь гаилә – Зөлфия һәм Альберт Зариповлар белән дә сөйләштек.

Зөлфия – шушы авыл кызы. Белеме буенча мал табибы. Укуы тәмамланмаганга күрә әлегә фельдшер вазыйфасын башкара. Ире Альберт исә тумышы белән Кукмараның үзеннән.

– Мин район үзәген яратып бетермәдем. Күңелем барыбер авылга тартты. Аннан соң, Кукмарада иремә эш табу авыррак булды, шуңа күрә улыбыз туугач авылга кайтырга булдык. Дөрес, фатирда яшәгән кешегә авылга кайту җиңел булмады. Ике ай узгач, Альберт та авылдагы тормышны ярата башлады. Монда калырга теләге барлыгын белгәч, хуҗалык җитәкчесе Нәфыйк Хөсәеновка эш сорап мөрәҗәгать иттек. Ирем оператор булып урнашты, – ди Зөлфия.

Әлеге программа турында да яшьләргә хуҗалык җитәкчесе җиткергән. Гариза язып тапшырганнан соң, якынча 1,5 ел эчендә яңа йортка күченгәннәр.

– 30 ноябрьдә үз йортыбызга кердек. Без бик канәгать. Барысы да балалы гаиләләргә уңайлы булсын дип эшләнгән. Һәр нәрсә үз урынында. Обойларга кадәр ябыштырылган иде. Безгә бары тик вак-төяк эшләрне карыйсы һәм җиһазлар гына сатып аласы булды. Йорт янында хәтта мунчасына кадәр бар иде, – ди Зөлфия Зарипова.

Әлеге гаиләләр йортны биш елдан соң үзләренә рәсмиләштерә алачак. Шул вакыт узгач, йортның – 10, ә ун елдан соң 1 процентын түләп, тулысынча үзләренеке итәргә мөмкинлек булачак.

– Икебезгә дә эшебез ошый. Авылдан китү турында уйлаганыбыз да юк, – ди Зөлфия. – Вахитта яшәү рәхәт. Барысы да якын урнашкан. Балабызга бакча, мәктәп бар. Кибет, клуб, парк. Асфальт юл салынган. Ә иң мөһиме – яхшы хезмәт хакы булган эшебез бар. Ирем белән икебез кулга 60 мең сум акча алабыз. Миңа калса, авыл җире өчен яхшы хезмәт хакы бу. Ирем дә авылны үз итте. Аралашырга дуслары да бар. Кукмарага баргач та, тизрәк авылга, үз йортыбызга ашкынып кайта.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КИЧӘ КУЙГАН БҮГЕН ТӨШСӘ...

СЫЙФАТСЫЗ МЕДИЦИНА ХЕЗМӘТЕ ӨЧЕН АКЧАНЫ НИЧЕК КИРЕ КАЙТАРЫРГА?

Казанда яшәүче Алсу Вәлиева бу көннәрдә башкаладагы шәхси клиникаларның берсендә тешен яматкан. Ләкин стоматологтан кайтканга өч көн дигәндә, пломба килеп төшкән. Шәхси клиникага шалтыратып, хәлне аңлаткач, аңа бу хезмәт өчен акчасын кире кайтарудан баш тартканнар. Өч көнгә дә чыдамаган пломбаны яңадан куеп, хаталарын төзәтергә җыенмауларын да әйткәннәр. Килешүдә язылган хезмәт күрсәтелгәнме – күрсәтелгән, калганы аларның эше түгел, янәсе. Мондый кыен хәлдә калган кешегә нәрсә эшләргә?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Юрист Илнур Гарифуллин фикеренчә, андый чакта тимерне кызуында сугарга кирәк. «Закон буенча табиб бер ай элек үзе куеп җибәргән пломбаны да, төшкән очракта, бушлай яңадан куярга тиеш. Белгеч күрсәткән хезмәттән канәгать булмавыгызны эш барышында яки процедурадан соң ук белдерсәгез яхшы. Кимчелекләрне күрә торып, моның белән килешкән булсагыз, алга таба сезгә бу хезмәтне күрсәткән оешмадан нәрсә дә булса өмет итүдән мәгънә булмаячак. Алсу Вәлиева очрагында хезмәтнең сыйфатсыз күрсәтелгәнлеге соңрак ачыкланган. Шуңа күрә монда килешү төзегәндә язылган шартларга таянырга туры киләчәк. Закон буенча, хезмәтнең сыйфатсыз күрсәтелгәнлеге соңрак ачыкланса, кеше килешүдә күрсәтелгән гарантия вакыты дәвамында түләгән акчасын кире кайтаруларын яки хезмәтне яңадан, бушлай күрсәтүләрен таләп итә ала. Килешүдә гарантия вакыты күрсәтелмәгән булса, шушы хезмәт күрсәтелгән көннән башлап, ике ел эчендә шундый дәгъва белдерергә мөмкин», – ди юрист.

Түләүле медицина оешмасында сыйфатсыз күрсәтелгән хезмәт өчен акчаны ничек кайтарырга? Илнур Гарифуллин эшне шәхси клиникага язмача дәгъва белдерүдән башларга киңәш итә. Ул иреклe формада языла. Ике нөсхәдә булырга тиеш. Анда шәхси мәгълүматлардан тыш, сезгә биредә нинди хезмәт күрсәтелгәнлеге, аның өчен күпме акча түләвегез, табиб күрсәткән хезмәттән соң нинди проблемалар башлануы турында тәфсилләп язарга кирәк. Ахырдан шушы зыян өчен клиникадан нәрсә таләп итүегезне дә конкрет күрсәтергә онытмагыз. Сез алардан сыйфатсыз хезмәт өчен түләнгән акчаны кире кайтаруларын яисә шул ук хезмәтне яңадан бушка күрсәтүләрен таләп итә аласыз. Язмача дәгъвадан тыш, хат эченә хезмәт өчен түләнгән чек күчермәсен дә салырга онытмагыз. Шикаять хатын медицина оешмасына шәхсән үзегез илтеп тапшырырга яки заказлы хат итеп җибәрергә кирәк. Хатны алулары турында белдерү кәгазе дә алырга онытмагыз.

«Әгәр медицина оешмасы сезнең таләпләр белән килешмәсә, аларга читтәге башка белгечтә узган тикшеренү нәтиҗәләрен дә күрсәтә аласыз. Анда ул белгечнең сезнең сәламәтлеккә нәкъ менә шушы оешмада күрсәтелгән хезмәттән соң зыян килгәнен раслаган булуы кирәк. Шушы хат һәм дәлилләрне тәкъдим иткәннән соң, медицина оешмасы сезгә ун көннән соң җавап бирергә тиеш. Әгәр алар сезнең таләпләрне үтәүдән баш тартса, мәсьәләне суд аша хәл итәргә туры киләчәк. Шул ук вакытта Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Росздравнадзор) идарәсенә дә шикаять белдерсәгез була», – ди юрист.

Бу очракта иң катлаулысы шул: шәхси оешмада күрсәтелгән нинди хезмәтнең сыйфатсыз саналуын билгеләгән төгәл генә критерийлар юк. Гамәлдәге законда табиб хатасы дигән төшенчә дә төгәл билгеләнмәгән. Шуңа күрә бу юнәлештәге низагларны җиңел генә хәл итәм димә. Соңгы арада Россиядә медицина хезмәтенә, аеруча түләүле клиникаларда күрсәтелгән хезмәт сыйфатына дәгъва белдерүчеләр саны арткан. Халык күбесенчә шәхси клиникаларда күрсәтелгән косметология хезмәте сыйфатыннан (60 процент) зарлана икән. Зарланучыларның күбесендә әлеге процедуралардан соң аллергия пәйда булган. Соңгы арада шәхси стоматология клиникаларында күрсәтелгән хезмәтләргә дә дәгъва белдерүчеләр саны арткан.

Дәва эзләп, шәхси медицина оешмасына мөрәҗәгать итәргә уйлаган кеше берничә кагыйдәне истә тотарга тиеш, ди белгечләр. Иң элек сез сайлаган клиника турында тулы мәгълүмат туплагыз. Мондый эшчәнлек алып бару өчен лицензиясе бармы-юкмы? Моны Росздравнадзор идарәсенең рәсми сайтында (www.roszdravnadzor.gov.ru) клиниканың исемен, ИНН, ОГРН номерларын язып тикшереп карарга була. Сез мөрәҗәгать итәргә җыенган табиб биредә ким дигәндә өч ел эшләгән булса яхшы. Табиблар гел алмашынып торса, шикләнергә җирлек бар. Тәҗрибәле белгеч кирәкле даруларны язып кына бирергә тиеш. Әгәр табиб сезгә аның кул астында булган фәлән дару, мазьны сатып алырга тәкъдим итә икән – баш тартыгыз. Бу очракта андый белгечнең үз эшен ни дәрәҗәдә сыйфатлы башкаруына да шикләнергә җирлек бар.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БЕРКЕМ ДӘ ОНЫТЫЛМЫЙ

«Хәтер китабы» редакциясе оешуга 30 елдан артык вакыт үтеп китте. Бу инде 30 ел буе республикабызның данлы еллар тарихын бөртекләп туплау, китап итеп чыгарып, киләчәк буыннарга җиткерү дигән сүз.

1989 елда илдә Бөек Җиңүнең 50 еллыгын үткәрү буенча чаралар планы эшләнеп, Бөтенсоюз Хәтер китабын булдыру да тәгаенләнә. Моның өчен барлык төбәкләрдә махсус редакцияләр оештыру тәкъдим ителә. Татарстанда редакция КПССның өлкә комитеты каршында, ул вакытта (һәм хәзерге көндә дә) Татарстанда актив эшләп килгән эзләнү хәрәкәте нигезендә оештырыла.

Эшнең башы бик болгавыр заманга эләгә. Редакцияне финанслау мәсьәләсе берничек тә хәл ителмәгән булу сәбәпле, эш нигездә коры энтузиазмга корыла. Бина булмау да зур кыенлыклар тудыра. Җиде тапкыр күченергә туры килә. Әмма коллектив бер генә көнгә дә эшен өзми. Шушы вакытта республикабыз хөкүмәте, редакцияне үз канаты астына алып, бюджеттан финанслау турында карар кабул итә.

Сугыштан кайтмаганнарның Хәтер китабына материаллар туплау төрле архивларда – хәрби комиссариатлар, авыл советлары, ветераннар һәм эзләнү оешмалары архивларында сакланган документлар, моннан тыш гаиләләрдә сакланган мәгълүматлар нигезендә оештырыла. Җирле газеталарга, КГБ архивына мөрәҗәгать итәргә туры килә.

Нәкъ шул вакытта Мәскәүдә Оборона министрлыгы тарафыннан Бөтенсоюз документлар һәм архив хезмәте фәнни-тикшеренү институты ачыла. Әлеге оешма сугыштан кайтмаганнар турында барлык документларны үзендә туплый. Сугышта һәлак булган һәм хәбәрсез югалган якташларыбыз турында документларның күчермәләрен без дә шуннан ала башладык. Ни кызганыч, әлеге документларда хата-төгәлсезлекләр күп очрый, бу бигрәк тә татар исем-фамилияләренә кагыла.

Эшче төркемне инде ул чакта ук республикада билгеле журналист, тәҗрибәле эзләнүче Михаил Черепанов җитәкли. Эшне башлаганда Татарстаннан сугышка 145 меңләп сугышчы чакырылып, аларның 87 меңе әйләнеп кайтмаган дип саналса, Хәтер китабы өчен исемлекләр төзү барышында бу саннарның чынбарлыктан нык ерак икәнлеге ачыклана. 1993 елларга, республика буенча бердәм электрон база булдырганнан соң, югалтулар санының 350 мең тирәсе, сугышта катнашкан якташларыбызның саны 700 мең булуы ачыклана. Шуларның 560 меңе Бөек Ватан сугышы елларында фронтка җибәрелә, 140 меңе срочлы хезмәттә булып, армия сафларында килеш фронтларга эләгә.

Шушы бердәм электрон база нигезендә Татарстанның 27 томлык «Хәтер» китабы нәшер ителде. Бу эш бүгенгәчә дәвам итә, якташларыбызның һәлак булуы, кайда җирләнүләре турында, мәсәлән, соңгы вакытта әсирлектә үлүчеләр турында яңа мәгълүматлар табылды, һәм алар Бөек Җиңүнең 75 еллыгына атап әзерләнгән 28 нче томга кертелде.

1999 елда Татарстан Министрлар Кабинеты карары нигезендә редакциягә яңа зур эш – Татарстан Республикасының сәяси репрессия корбаннары Хәтер китабын төзү бурычы йөкләнде. 2000 елда бу китапның беренче томы дөнья күрде, бүгенгә 28 том басылып чыкты. Бу китапта сәяси җинаятьләр өчен җаваплылыкка тартылган 51 меңнән артык якташыбызның, административ рәвештә репрессияләнгән, сөргенгә җибәрелгән 15 меңнән артык гаилә әгъзаларының (аларның саны 200 меңнән артык) исеме мәңгеләштерелгән, бу эш әле дә дәвам итә.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы архивларында сакланган шәхси карточкаларны өйрәнеп, административ рәвештә репрессияләнгән 4 меңнән артык гаилә турында мәгълүмат табылды. Эчке эшләр министрлыгының реабилитация бүлегенә мөрәҗәгать итеп, аларны аклауга ирештеләр. Милли архивның административ репрессияләр буенча фондларын өйрәнү нәтиҗәсендә, тагын 1,5 мең гаилә табылды.

Бөек Җиңүнең 60 еллыгын каршылаган көннәрдә без «Алар илгә Җиңү алып кайтты» Республика Хәтер китабын нәшер итүгә керештек. Бу китап – Бөек Ватан кырларында сугышып, Җиңү яулап, илгә әйләнеп кайткан якташларыбызның исемлеге. Бүгенгә бу проект буенча 49 том дөнья күрде, аларда Бөек Ватан сугышында катнашкан 220 меңнән артык якташыбызның исеме аталган, һәм бу эш бүген дә дәвам итә.

«Татарстан Республикасының тыл геройлары» китабын нәшер итү турында да Татарстан Хөкүмәте карары кабул ителде. Бүгенгә 8 том нәшер ителгән, аларда 58 меңнән артык якташыбызның исеме мәңгеләштерелгән. 2019 елда, Әфганстан Республикасы территориясенә совет гаскәрләренең чикләнгән контингентын кертүнең 40 еллыгына һәм аның чыгарылуының 30 еллыгына багышлап, редакция тарафыннан «Әфганстанда сугыш хәрәкәтләре ветераннарының Хәтер китабы (1979–1989)» биографик сүзлеге нәшер ителде.

Редакция тарафыннан әзерләнеп нәшер ителгән «Татарстан Бөек Ватан сугышы елларында (1941–1945)», «Татарстан – Сталинградү», «Социалистик Хезмәт Геройлары», «Дан орденының тулы кавалерлары», «Оныклар каһарман бабалары турында», Чернобыль атом электр станциясендәге һәлакәтне ликвидацияләүдә катнашучыларның Хәтер китабы (әлеге басмада 4 мең тирәсе исем аталган), «Татарстанның сугышчан канатлары» һ.б. басмалар да үткәннәребезне онытмаска, хәтерне яшәтергә юнәлтелгән.

Нәфисә ГАБДРАХМАНОВА

Ана теле – бүләккә

Күптән түгел мәктәпләргә танылган язучылар турында плакатлар таратылса, бакчалардагы сабыйларга музыкаль китаплар әзерләнгән. Тагын нинди бүләкләр көтә?

Төп игътибар балаларга юнәлтелгән. Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе, Татарстан китап нәшрияты тарафыннан әзерләнгән хезмәтләр татар балаларын туган телгә җиңел итеп өйрәтүне күздә тота. Алар барысы да мавыктыргыч итеп эшләнгән, татарлык рухын сеңдерер өчен менә дигән. Тел бетә дип кул кушырып утырмыйча, төрле формаларны эзләргә тырышалар. Балаларга заманча әйберләр кызык. Шуңа күрә музыкаль аудио китаплар, магнит такталар да булачак икән.

– Мәшһүр татар шәхесләренең сурәтләре төшерелгән һәм алар турында кыскача мәгълүмат язылган пластик һәм алюминий кысалы плакатлар әзерләнеп, мәктәпләргә таратылган. Барлыгы 15 шәхесне эченә ала ул. Алар арасында Кол Гали, Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Галиәсгар Камал, Һади Такташ һәм башкалар бар. Барысы да укучыларда кызыксыну уятырдай зәвыклы итеп башкарылган, – ди комиссия әгъзасы, Татарстан китап нәшрияты җитәкчесе Илдар Сәгъдәтшин.

Сабыйлар өчен пластик плакатлар әзерләнеп, республиканың 950 бакчасына җибәрелгән. Һәр бакчага 10 плакаттан җыелган 1 комплект дигән сүз бу. Анда Бари Рәхмәт, Роберт Миңнуллин, Резеда Вәлиева, Рафис Корбан һәм башкаларның портретлары, аларның шигъри юллары, шул юлларга мөнәсәбәтле рәсемнәр урын алган.

Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе һәм «Татнефть» җәмгыяте ярдәмендә Татарстан китап нәшрияты яшь укучылар белергә тиешле 17 мөһим әдәби әсәрнең электрон китапларын булдырган. Әлеге әсәрләрне «ЛитРес» һәм Татар әдәбияты үзәге порталларында бушлай укырга мөмкин. Шулай ук, Татарстан китап нәшрияты Россиядә билгеле «Росмэн» һәм «Эксмо» нәшриятларының яшь укучыда популяр булган энциклопедия сериясен татарчага тәрҗемә итеп бастырган. 18000 китап балалар бакчаларына таратылган. Бу эш 2022 елда да дәвам иттереләчәк. «Росмэн» нәшриятының тагын 10 китабы татар теленә тәрҗемә итеп бастырылачак.

Музыкаль модуль урнаштырылган катыргы китаплар да әзерләнгән. Сабыйлар татарча авазлар, сүзләр ишетә, аларны дөрес итеп әйтергә өйрәнә ала. Әлеге сериядә Рабит Батулланың «Койрыксыз бака», Җәвад Тәрҗемановның «Йомшак су, йөгерек су», Мәрзия Фәйзуллинаның «Чебиләр зарядкасы» әсәрләре кергән. Китаплар 33000 нөсхәдә бакчаларга таратылган. Болар барысы да татар телен уен аша өйрәтергә ярдәм итә.

Быел нәшрият интерактив магнитлы карточкалар әзерләп бастырырга ниятли. Алар да бакчаларга барып ирешергә тиеш. Бу карточкалар ярдәмендә сабыйлар гаилә әгъзаларын, аш-су, өс киемнәрен танырга, ел фасылларын истә калдырырга өйрәнә ала. Шулай ук магнит тактага фломастер белән язарга, анда проектор ярдәмендә фото һәм видеоматериаллар карарга була.

Сәрия МИФТАХОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының тарихи һәм мәдәни мирасын саклауга мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле фәнни эшчәнлеге һәм актив иҗтимагый хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесенең фәнни җитәкчесе **Хәкимов** Рафаиль Сибгать улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Тимофеев** Валерий Геннадиевич; татар халкының мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасының Рәшит Ваһапов исемендәге Татар мәдәнияте иҗтимагый фонды директоры **Фәттахов** Рифат Әхмәт улы; мәдәниятне һәм сәнгатьне үстерүдәге казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Казан дәүләт мәдәният институты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе театр, кино һәм телевидение факультетының театр иҗаты кафедрасы профессоры **Хамматова** Эльмира Мифтах кызы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының оештыру бүлеге баш белгече **Вилданова** Венера Нурислам кызы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Бәтке авыл җирлеге башлыгы **Динмөхәммәтов** Фәнис Мансур улы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Исламова** Гүзәлия Нил кызы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Чуаш Бизнәсе авылыннан алты бала анасы **Фомина** Елена Валентиновна **Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале** белән бүләкләнде.

***

Җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе хезмәткәрләре: кадрлар бүлеге җитәкчесе, юстиция полковнигы **Вәлиева** Фәридә Камил кызы, криминалистика бүлеге җитәкчесе урынбасары, юстиция полковнигы **Егоров** Андрей Николаевич, Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераны **Гыйматдинов** Әнәс Кыям улы; «Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең «Боровое Матюшино» шәһәр яны комплексы» дәүләт бюджет учреждениесе директоры **Мөхәммәтханов** Наил Миннияз улы; хезмәт ветераны **Долганова** Татьяна Федоровна, «Россия пенсионерлары берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Апас муниципаль районындагы җирле бүлекчәсе советы рәисе **Кәлимуллин** Фәрит Кәлимулла улы, «Зеленодольск сөт эшкәртү комбинаты» акционерлык җәмгыяте «ЗМК» әзер продукция складының төягеч машина йөртүчесе **Макаров** Владимир Сергеевич, «АК-БАРС Мед» иминиятләштерү компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте Саба районындагы вәкиллегенең офис буенча өлкән хезмәткәре **Таипова** Флера Фәрит кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Азнакай киемнәре» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Бәзгетдинов** Рөстәм Фәрит улына **«Татарстан Республикасының атказанган җиңел сәнәгать хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Тәтеш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең акушерлык физиологиясе бүлекчәсе мөдире – табибы – акушер-гинекологы **Гайнуллина** Татьяна Александровнага, «Зәй үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең хирургия бүлекчәсе мөдире – табиб-хирургы **Морзагов** Мөхәммәд Али улына, «Чистай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы **Мостафин** Рәис Роберт улына, «Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге Республика йогышлы авырулар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бүлекчәсе мөдире – табиб-инфекционисты **Павлова** Татьяна Юрьевнага **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Актаныш» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең машина белән сыер саву операторы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Миңнуллина** Тәнзилә Миншәех кызына **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе директорының спорт эше буенча урынбасары **Гобәева** Татьяна Геннадьевнага, Казан шәһәренең «Ак Бүре» физкультура-спорт берләшмәсе» муниципаль автоном учреждениесе директорының спорт эше буенча урынбасары **Мәһдиева** Гөлнара Фирдинат кызына, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Мамкин** Сергей Геннадьевичка, «Татарстан Республикасы Автомобиль спорты федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы әйдәүче белгече **Мөбарәкшина** Диана Наил кызына, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Зәй» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Ревин** Алексей Владимировичка, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Старт» чаңгы ярышлары спорт мәктәбе муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Хафизов** Шамил Мөдәрис улына **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының 2 номерлы лицей муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директорының уку-укыту эше буенча урынбасары **Бронникова** Наталья Владимировнага, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Биектау урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры, рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Камалиева** Рәмзия Усман кызына **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Связьинвестнефтехим» акционерлык җәмгыяте генераль директорының финанс институтлары белән эшләү буенча урынбасары **Терентьев** Владимир Александровичка; Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары **Хәбибуллина** Лариса Васильевнага; «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Идарә, икътисад һәм финанс институтының икътисад теориясе һәм эконометрика кафедрасы ассистенты **Шәфигуллина** Галия Илдар кызына **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Арчада яшәүче кадерле әниебез, дәү әниебез ХӘМИДУЛЛИНА Мөнирә Вәли кызын ихлас күңелдән юбилее белән котлыйбыз!

Син безнең өчен һәрчак олы җанлы, киң күңелле кеше, таянычыбыз, ышанычыбыз, киңәшчебез, җылы кояшыбыз, рух чишмәбез, яшәү өлгебез. Сиңа язгы кояш нурларыдай аяз көннәр, исәнлек-саулык, җан тынычлыгы, озын гомер, ак бәхетләр телибез! Картлыгың бары тик шатлыкта гына үтсен. Гел шулай көләч, ягымлы бул. Безне сөендереп, озын-озак яшә!

Котлы булсын юбилееӊ,
Бәхетләреӊ килсен күренеп.
Куанычлар гына юлдаш булсын,
Яшә шатлыкларга төренеп.

Иң изге теләкләр белән, Хантимировлар, Зиннәтуллиннар, Хәмидуллиннар

Спорт кына түгел бу

Күңелнең Кытайда чагы

Пекинда Кышкы Олимпия Уеннары ахырына якынлаша. Шатландыра да, борчуга да сала быелгы ярышлар. Ә сез Олимпиаданы карыйсызмы?

Фәнзилә МОСТАФИНА, журналист:
– Чынлап торып белеп караган беренче Олимпиадам – 2006 елда Туринда узган Кышкы Уеннар. Анда биатлончы һәм чаңгычы кызларның, фигуралы шуучыларның алтын медаль китергән чыгышлары һаман да хәтердә. Аннан соң «Сабантуй» журналы Кышкы Олимпия Уеннары буенча уздырган викторинада җиңеп, футболка оттым. Ул вакытта интернет юк иде, китапханәдән Олимпия Уеннары тарихы турында китап табып, җавапларны шуннан тапкан идем. Шуннан соң Олимпиадаларны бер дә карамый калган юк. Биатлон, чаңгы ярышларын, хоккейны болай да карап барам, ә Олимпия Уеннарын, әлбәттә, икеләтә кызыксыну белән күзәтәм. Керлинг, шорт-трек, сноуборд кебек гадәттә бик каралмый торган спорт төрләрен дә күзәтеп барам. Әлбәттә инде, беренче чиратта үзебезнекеләр өчен җан атам, татар исем-фамилияле спортчылар булса, аерым бер горурлык кичерәм. Спортчыларның нинди киртәләр аша үтеп, нинди авырлыкларны җиңеп, уңышка ирешүләре турында укырга яратам.

Ренас КӘЛИМУЛЛИН,
көрәш буенча дөнья чемпионы:
– Пекин белән Мәскәү вакытында аерма зур булгач, Олимпия Уеннарын туры эфирдан күзәтеп барырга мөмкинлек юк. Әмма хәзер уңайлы бит – текстлы репортажлар бар, аларын укып барам. Берәр кызыклы ярыш булса, трансляцияне кабатлауга куябыз да гаилә белән кич утырып карыйбыз. Электән калган бер гадәттер инде бу. Әле менә соңгы арада чаңгычылар, биатлончылар өчен җан аттым, фигуралы шууны да күзәттем. Тиздән хоккей буенча кызыклы уеннар башлана – аларын да карарга иде исәп. Гомумән, нинди генә спорт төрен алсак та, барысын да читтән булса да күзәтеп, үзебезнекеләр өчен җан атабыз. Аеруча үзебезнең татар кызы Камилә Вәлиева тирәсендәге шау-шу борчый. Ахыры ни белән бетәр…

Рания ГЫЙЛЕМХАНОВА, укытучы:
– Без спорт уеннарын карыйбыз гына түгел, ә бик яратабыз. Дөнья чемпионатлары, Гагарин Кубогы өчен ярышлар һәм Олимпия Уеннары минем гаиләнең игътибар үзәгеннән читтә калмый. Кечкенәдән әти белән әни спортка шулай мәхәббәт уяттылар. Хәзер Олимпия Уеннары кызганнан-кыза бара. Гаиләбез белән фигуралы шуу, хоккей, биатлон, шорт-трек һәм чаңгы ярышларын бик яратып карыйбыз. Әти белән энем хоккейчылар өчен җан атса, әни белән мин фигуралы шууга өстенлек бирәбез. Соңгысы белән бәйле яңалыкларны ишетми һәм күрми калган кеше юктыр, мөгаен. 15 яшьлек өметле, талантлы уенчыбыз өстенә нинди авырлыклар төште бит. Бу хәлләрнең Камилә өчен яхшы тәмамлануын теләп калам. Анна, Александра һәм Камиләнең беренче уеннары бит, күңелем белән мин шул аренада булачакмын. Безнең уенчылар шәп чыгыш ясый. Аларга бары тик басып алкышлар яудырырга һәм рәхмәт әйтергә генә кала! Медальләр саны буенча без беренче унлыкта бит! Бу – бик яхшы күрсәткеч, миңа калса.

Илшат ГАРИФУЛЛИН
(Кайбыч районы Кошман авылы):
– Кышкы Олимпия Уеннарын авылда да карап барабыз – телевидение, интернет заманы бит. Әлбәттә, Россия җыелма командасы өчен җан атабыз. Ир кешеләргә бигрәк тә хоккей, чаңгычыларны күзәтеп бару кызык инде. Әле менә күптән түгел ир-егетләребез чаңгы эстафетасында 42 елдан соң беренче тапкыр алтын медаль яулады, кызларыбыз да сынатмады. Спортка көчле яшьләрнең җәлеп ителүе сөендерә, билгеле. Хоккей командасына килгәндә, алар өчен дә җан атабыз, әлбәттә, ләкин әлегә алга китеш күренми. Тәҗрибәләре җитеп бетми. Шулай да өмет юк түгел. Аннан соң Камиләбезне карап барабыз. Нәсел җепләре Апас районына килеп тоташканга күрә бигрәк тә борчылабыз. 15 яшьлек кыз өчен бик көчле сынау булды бу. Спорт белән сәясәтнең кушылуы киләчәк буын спортчылары өчен бер дә яхшы түгел шул.

Яшел Үзән

ЯКТАШЛАР – ЭЛЕМТӘДӘ

Руфия Мөхетдинова Казанда яши, туган җире – Яшел Үзән районы Урысбага авылының блогын алып бара. Шәһәрдә яшәп, авыл тормышын ничек, ни дәрәҗәдә белеп була? Мондый гамәлнең авыл халкы өчен файдасы бармы, кирәкме ул? «Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән «Матбугат.ру» порталы оештырган «Татар. Блогер» бәйгесенең «Иң яхшы авыл аккаунты» номинациясе җиңүчеләре арасына кергән Руфия белән әнә шундыйрак сорауларга җавап эзләдек.

Күңел эше

– Авылга кайткач, гел матур күренешләрне, су буйларын, чишмәләрне фотога төшерергә яратам мин. Бервакыт күбәеп киттеләр. Телефонның хәтере җитми башлады. Алып ташларга да кул бармый. «Нишлим икән?» – дип аптырап йөргәндә, «Матбугат.ру» сайты җитәкчесе Данил Сәфәров «Инстаграм» алып бару буенча укулар үткәрде. «Үз авылыгызның аккаунтын булдырыгыз да шуны алып барып карагыз», – дип киңәш бирде. Җәй көне ялга кайткач, кызыксынып, үзем өчен генә дип, авыл битен булдырдым. «Туган ягым Урысбагам» аккаунтының беренче постына туганым Альмира апа башкаруында «Урысбагам» җырын куйдым. Авылдашыбыз Фәнис Шакиров аңа клип та төшергән иде.

Баштарак язылучылар бик аз булды, авыл халкы аңлап та бетермәде кебек. Аның каравы тора-бара бу эш үземә ошап китте. Альбомнардагы аклы-каралы фотоларны урнаштыра башладым. Авылдашлар да тартылды: флешмобларда катнаша башладылар. Төрле бәйрәмнәрдә төшерелгән фотолар җибәрүләрен дә сорадым. 23 февраль – Ватанны саклаучылар көне уңаеннан «Солдатта булган диләр» дигән флешмоб игълан иттем. Анда армия сафларында хезмәт иткән 100дән артык якташыбызның фотолары урнаштырылды. 9 Май алдыннан «Урысбага авылы батырлары» хэштегын булдырдым. Атна буена ветераннарның фотолары килеп торды. #Җиләкле Урысбага, #Минем кабак иң зуры, #Ямьле безнең авыл өйләре кебек акцияләр дә төркемне җанландырып җибәрде. Мәктәп тормышына бәйле фотолар да күп килә. Шулай итеп, авыл халкы, комментарийлар язып, рәхәтләнеп аралаша башлады. 2019 елдан бирле 900дән артык пост урнаштырылды инде. 1000нән артык язылучыбыз бар. Тик мин сан артыннан куарга кирәкми дигән фикердә. Монда нигездә Урысбага чишмәсенең суларын эчеп үскән, бер авыл һавасын сулап, бер юллардан йөргән якташларыбыз аралашырга тиеш дип саныйм.

Элек авыл төркемнәре аз иде. Бигрәк тә пандемия чорында авыл җирлекләре, клубларның үз аккаунтлары яңгырдан соң чыккан гөмбә кебек артты. Тик алар барысы да бер калыпта, билгеле бер кагыйдәләргә буйсына, чикләүләр дә бар. Мин алып бара торганында бернинди чикләүләр дә юк. Шуңа халык күбрәк тартыла, язылa, аралаша дип уйлыйм. Чыннан да, мактанып утырып кына булмый бит, чеметкәләп ала торган постларны да куярга туры килә. Кайдадыр юллар начар чистартылган, кайдадыр чүп өемнәре күбәйгән – болары да авыл тормышы. Авылдашлар һәр күренешкә үз фикерләрен белдерәләр.

Авыл аккаунты ул – бик күп вакытны ала, финанс яктан түләнми, әмма рәхәтлек китерә торган күңел эше. Әлегә кызыксынуым бик көчле. Үзем өчен яңалыклар ачам, өйрәнәм. Авылдашлар белән гел элемтәдә торам, рәхмәтләрен дә җиткерәләр. Бәйгедә җиңү яулау авылыбызны бигрәк тә танытты. «Башваткыч» тапшыруында да катнашырга насыйп булды. Күп кенә матбугат чараларында кечкенә генә авылыбызның исеме яңгырады. Шуңа күрә мондый блогны авылда яшәп алып барасыңмы, әллә инде шәһәрдәме – бернинди киртәләр юк дип уйлыйм. Иң мөһиме, үзеңдә – теләк, халыкта активлык булу кирәк.

Яшерен-батырын түгел, блогны алып бара башлаганда, арбаны үзем генә тарттым. Хәзер исә авыл җирлеге башлыгы Хәйдәр Сибгатуллин, мәдәният йорты мөдире Люция Садриева штаттан тыш хәбәрчеләр кебек. Мәчеттәге яңалыкларны Илшат Шиһапов җиткерә. Соңгы елларда авылдашыбыз Рөстәм абый Сәйфуллин, Казан, Мәскәү, Петербург архивлары белән аралашып, авыл тарихына бәйле материаллар әзерли башлады, Аларны #Урысбага тарихы хэштегы белән урнаштырып барабыз. Киләчәктә бәлки китап чыгарырга да насыйп булыр. Тагын бер авылдашыбыз Фәнис Шакиров, авыл күренешләрен, бәйрәмнәрне гел фото-видеога төшереп, безнең белән уртаклаша.

Интернетлаштык

Блогка читтә яшәүче якташлар күбрәк язылa. Алар еш кайта алмыйлар. Ә интернет аша күзәтү бик тә уңайлы. Ярдәм сораучылар да бар. Аккаунтны сугыш елларында Красноярск шәһәрендә яшәп калган авылдашыбызның кызы эзләп тапкан. Шалтыратты. «Әтием күптән вафат, нәселебезне барлыйбыз. Үзем исән чакта шәҗәрәбезне төзисем килә», – ди. Бер сәгать аралаша торгач, аның ирем ягыннан туган кеше булуы ачыкланды. Узган ел бер апа: «Әтием сезнең авылдан иде. Мин Урысбагада ике яшьлек чагымда гына булганмын. Әтиебез үлгәч, элемтәләр өзелде. Хәзер авылда туганнарыбыз бармы икән?» – дип хәбәр җибәргән. Шул ханымга әтисенең апасының телефон номерын табып җибәрдек. Хәзер аралашып торалар.

Блогның тагын бер уңайлы ягы бар: берәр өмә үткәрәсе булса, игъланны алдан куябыз. Кайтучылар күп була. Узган ел зират капкасын да авылдашлардан җыелган сәдака акчасына яңарттык. «Минем авылга кайтып йөрергә кешем юк, әмма акча күчерер идем», – дип язучылар да булды. Халыкка юбилярларны котлау да бик ошый. Киләчәктә якташлар белән туры эфирлар да алып барырга уйлыйм. Бер сүз белән әйткәндә, авыл блогы ул – авылдашларны, якташларны туплап тору мәйданы.

Блогны алып бара башлаган чорда авылда интернет бик начар тота иде, авыл башына чыгып, йорт түбәсенә менеп, пост урнаштырып йөргән чаклар да булды. Хәзер күп кешедә интернет бар. Күбесе «Инстаграм»га теркәлгән. Баштарак, юк, кирәкми, дип каршы килеп маташсалар да, кызыксынулары җиңде: үз әтием белән әнием дә кушылдылар. Әнием хәзер киңәшләрен дә биреп тора.

Дөнья мәшәкатьләре белән гомер дигәнең шундый тиз уза икән ул. Кайчагында авылның матурлыгына, урман-болыннарына күз төшерергә, кошлар сайравын ишетергә вакыт җитми кебек. Әти-әниләре вафат булуга тиз генә йорт-җирләрен сатып китүчеләр дә байтак. Андый кешеләрне туктатасым, уй-фикерләрен туган җирнең матурлыгына, нәсел, нигез төшенчәсенә юнәлтәсем килә. Авыл блогы мондый очракларда да ярдәмгә килә.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

АШАГАН БЕЛМИ,ТУРАГАН БЕЛӘ

Балтач

Яшәеш

Килешәсездер, хәзерге заманның иң кәттә һөнәр ияләре, кәсепчеләре булган эшмәкәрләрне бүген күпләр бик рәхәт яши дип саный. Нигә, акчалы кешенең абруе зур, беркемгә буйсынмыйлар, нәрсә белән шөгыльләнәселәре килсә, рәхим ит, – ирек, яхшы машиналарында йөриләр, зиннәтле йортларда яшиләр, чит илгә дә елга берничә тапкыр, кемнәрдер район үзәгенә, Казанга барган кебек кенә «чыгып керәләр»…

Тик моның беренче карашка гына шулай икәнен, тышкы кабык кына булганын, шушы байлыкны тудыру өчен көн-төн тырышырга кирәклеге турында гына күпләребез уйлап та карамый. Көндәлек мең проблема белән бәрелешкәннәрен, аларның һәркайсын мөстәкыйль хәл итәргә кирәклекне, күпсанлы, кайчакта бер-берсенә каршы килә торган кануннар чолганышында эшеңне бер генә тикшерү органы да тел-теш тидермәслек итеп алып барырга… һәм әле тагын бик күпне эшли белергә, күп белгечлекне берләштереп, һәркайсында оста булырга кирәклекне дә уйламыйбыз.

Балтач районының Нөнәгәр авылы эшмәкәре Фәйрүзә белән дә үз эшеңне булдыруның уңай һәм тискәре яклары турында сөйләшәбез.

– Әниләрем Нөнәгәрнеке булса да, алар Киров өлкәсе Малмыж шәһәрендә яшәде. Мин дә шунда туып-үстем. Нөнәгәр егете Рафис Закировка тормышка чыктым, менә утыз ел инде шунда яшибез, – ди ул. – Белемем буенча бухгалтер-икътисадчы идем. Нөнәгәрдә шәхси кибет ачтылар да, шунда эшли башладым…

2007 елда Закировлар, арендага бина алып, үз кибетләрен булдыра. Уңышлы гына эшләп китәләр. Әмма бина хуҗалары аренда вакытын озайтмый. Аптырап калмыйлар: бу юнәлешнең нечкәлекләрен аңлый-тоя башлаган Закировлар күрше Чутай авылында кибет төзеп чыгалар. Әллә ни ерак булмаган Ор авылында да элекке райпо кибетен арендага алалар. 2011 елда райпо әлеге кибет янәшәсендәге биналарны да аукционга куя. Аны да сатып алалар. Бер ел буе әйбәтләп ремонтлап, ул өлешендә «Бәйрәм» кафесы оештыралар. Ул еллар өчен кечкенә бер авылда заманча зәвыклы кафе ачылу үзе бер вакыйгага әйләнә. Бер караганда, әле авыл халкы күп бәйрәмнәрне өйдә генә үткәрергә күнеккән. Атнага бер-ике көн була торган туйларны да күпчелек район үзәгенә якын кафе-ресторанда үткәрә. Күпләр Фәйрүзәләрнең уңышка ирешәсенә дә шикләнә. Хәер, Фәйрүзә үзе дә яшерми. Ул да кафе табышка эшли алырмы икән дип уйлана, билгеле. Килгәннәрен көтеп кенә утырсаң, кафе да, кибет тә файдага эшләмәячәк. Көндәшләр дә тик тормый бит. Күрше авылда тагын бер кафе ачыла.

– Аларның үз клиентлары, безнең үзебезнеке, – ди Фәйрүзә. – Беркайчан бер-беребезгә көндәш итеп карамадык. Шөкер, башта туйлар-юбилейлар гына үткәрсәләр, соңгы елларда никах мәҗлесләре, сыйныфташлар очрашулары да бездә үтә башлады. Өйдә үткәрелә торган Коръән ашларына, башка бәйрәмнәргә салатлар, төрле ассортименттагы кабымлыклар, камыр ризыкларына да заказ бирәләр. Аларны өстәлгә алып кайтып куярлык дәрәҗәдә бизәп, матурлап та бирәбез. Бәлеш-гөбәдияләр, самсаларны бик күп пешерәбез. Аларны күчтәнәчкә алып барырга дип тә сорыйлар. Ярымфабрикатларны да яратып сатып алалар. Кафеда гади көннәрдә үзем генә эшлим. Камыр ризыклары пешерергә бик яратам. Иртән өчтә торып киләм дә рәхәтләнеп эшлим. Заказлар күп булганда, ярдәмчеләр чакырам. Шулай ук юбилей-туйларда, башка мәҗлесләрдә эшли-булыша торган командабыз бар. Алар инде ышанычлы кызлар, килешеп эшлибез. Заказлардан тыш пешкән камыр ризыкларын үзебезнең һәм башка кибетләргә дә чыгарабыз. Эшебездән үзем бик канәгать, яратып эшләгәнгәме, бер авырлыгын күрмим. Уңай ягы дигәндә, син – үз-үзеңә хуҗа. Беркемгә бәйле түгел. Тырышканың да, табышларың да үзеңә, югалтуларга да бер син гаепле… Ә менә җаваплылык бик зур. Мин гел әйтәм инде: йөз кешелек табын кору, аларга тиешле дәрәҗәдә хезмәт күрсәтү берни түгел. Әнә шул төне һәм икенче көне бик яман. Нинди генә хәбәр ишетермен икән дип, көне буе йөрәк табан астында була. Кеше сәламәтлеге өчен җавап бирәсе бит. Шөкер, моңа кадәр барысы да әйбәт булды, алга таба да исән-сау эшләргә язсын дип телим.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7080 данә
Гомуми тираж – 17126 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 223

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+